| СОВЕТ ГОРОДИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ГОРОДИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

Городище авылы

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 15 нче июне № 65/1

Депутатлар сайлауларын билгеләү турында Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге советы утырышы

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 10 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 105 статьясындагы 1 өлеше, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Уставының 12 статьясындагы 4 пункты, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Советы:

1.Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Городище авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын 2020 елның 13 сентябренә билгеләргә.

2. Әлеге карарны «Туган як» газетасында бастырып чыгарырга, аны кабул иткән көннән биш көннән дә соңга калмыйча, хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Городище авыл җирлеге бүлегендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка хәбәр итәргә кирәк.

Городище авыл
җирлеге башлыгы: С.А.Салифанов